ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2024 елның 23 декабре** **Чистай шәһәре** **№ 605**

Татарстан Республикасы "Чистай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясындагы 3.2 пунктының 4 абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар Татарстан Республикасының «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата 2025 елга һәм 2026-2027 еллар план чорына бюджеттан башлап кулланыла.

3. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 декабрендәге 823 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/ урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесенә йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов